**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 6, Иске Кади авылы, 423117

тел.(884396) 3-13-25 факс (884396) 3-13-25 email: Skad.Cmn@tatar.ru

№83 27.06.2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советының «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 21 февралендәге № 51 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 ноябрендәге № 329-ФЗ, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ Федераль законнар нигезендә Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 февралендәге № 51 карары белән расланган «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәгә (Советның 2018 елның 21 декабрендәге № 106, 2021 елның 30 сентябрендәге № 39, 2021 елның 17 декабрендәге № 48, 2023 елның 13 мартындагы № 79 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 2 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы (җаваплы) җирле үзидарә органының кадрлар бүлеге (кадрлар хезмәте) яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Иске Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.В.Мөктәсимов